**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевского ул., д.23, г.Лаишево 422610

Чернышевский урамы, 23 нче йорт Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

2025 елның 11 сентябре　　　　　　　　　　　　　1717 номер

# КАРАР

## Сокуры авыл җирлегенең Дачная урамы буенча ремонт эшләре барган вакытта юл хәрәкәтен ябу турында

«Юл хәрәкәте иминлеге турында» 1995 елның 10 декабрендәге 196-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясындагы 4 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2007 елның 08 декабрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, гражданнарның иминлеген тәэмин итү максатларында, карар бирәм.:

1. 2025 елның 15 сентябреннән 30 ноябренә кадәр Лаеш муниципаль районы Сокура авыл җирлегенең Сокуры авылында Дачная урамы буенча автомобиль юлы участогында автотранспорт хәрәкәтен туктатырга.
2. Юл хәрәкәтен чикләүләрне Лаеш районы буенча Эчке эшләр министрлыгының ЮХИДИ идарәсе белән килештерергә.
3. Хәрәкәтне ябу чорына:

- юл хәрәкәтенең кирәкле билгеләрен куярга;
- автотранспортны әйләнеп чыгу схемасын эшләргә һәм халыкка җиткерергә..

4. Әлеге карарны Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитетының инфраструктура үсеше буенча җитәкчесе урынбасары И. П. Шитовка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**